КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 октябрь г.Казань № 1259

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 16 февраль, 47 нче; 2007 ел, 14 июнь, 235 нче; 2008 ел, 26 ноябрь, 832 нче; 2009 ел, 27 февраль, 115 нче; 2009 ел, 8 апрель, 209 нчы; 2009 ел, 21 август, 571 нче; 2010 ел, 2 апрель, 229 нчы; 2015 ел, 4 февраль, 61 нче; 2015 ел, 12 март, 146 нчы; 2016 ел, 13 май, 305 нче; 2016 ел, 26 май, 359 нчы; 2016 ел, 19 октябрь, 762 нче; 2018 ел, 15 февраль, 90 нчы; 2018 ел, 24 март, 166 нчы; 2020 ел, 12 май, 379 нчы; 2021 ел, 17 февраль, 85 нче; 2022 ел, 7 март, 203 нче; 2022 ел, 13 август, 815 нче; 2023 ел, 11 июль, 809 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

икенче абзацта «һәм «Камалыштагы Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга» сүзләрен «Камалыштагы Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга, «Камалыштагы Сталинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2005 елның 1 гыйнварына кадәр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә баскан хәрби хәрәкәтләр инвалидларына, эчке эшләр органнарының, милли гвардия гаскәрләренең, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү учреждениеләренең хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә яралану, контузия алу яки гариплэнү аркасында инвалид булган хәрби хезмәткәрләренә һәм рядовой һәм башлык составлары затларына, хәрби хәрәкәтләр ветераннарына, һәлак (вафат) булган хәрби хәрәкәтләр инвалидларының һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзаларына, эчке эшләр органнарының, милли гвардия гаскәрләренең, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү учреждениеләренең хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә һәлак булган хәрби хезмәткәрләренең һәм рядовой һәм башлык составлары затларының гаилә әгъзаларына, әсирлектә һәлак булган, хәрби хәрәкәтләр районнарында хәбәрсез югалган дип билгеләнгән тәртиптә танылган хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларына, инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә.»;

2 пунктта:

«а» пунктчаның бишенче абзацында «һәм «Камалыштагы Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар» сүзләрен «Камалыштагы Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, «Камалыштагы Сталинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчаның икенче абзацында «эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының рядовой һәм җитәкчелек составы затларының» сүзләрен «эчке эшләр органнарының, милли гвардия гаскәрләренең, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарының рядовой һәм җитәкчелек составы затларының» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчаның дүртенче абзацында «эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының рядовой һәм җитәкчелек составы затларының» сүзләрен «эчке эшләр органнарының, милли гвардия гаскәрләренең, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнарының рядовой һәм җитәкчелек составы затларының» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидияләрне беренче чиратта алу хокукына II, III төркем хәрби хәрәкәтләр инвалидлары, шулай ук эчке эшләр органнарының, милли гвардия гаскәрләренең,

Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү учреждениеләренең хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә яралану, контузия алу яки гарипләнү аркасында II, III төркем инвалид булган хәрби хезмәткәрләре һәм рядовой һәм башлык составлары затлары, «Блокададагы Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, «Камалыштагы Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, «Камалыштагы Сталинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, һәлак (вафат) булган Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның гаилә әгъзалары, һава һөҗүменә каршы җирле оборонаның объект һәм авария командаларының үзоборона төркемнәренең шәхси составы арасыннан Бөек Ватан сугышында һәлак булган затларның гаилә әгъзалары, шулай ук Ленинград шәһәре госпитальләренең һәм хастаханәләренең һәлак булган хезмәткәрләренең гаилә әгъзалары, һәлак (вафат) булган хәрби хәрәкәтләр инвалидларының һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарының гаилә әгъзалары, хәрби хезмәт вазыйфаларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә һәлак булган эчке эшләр органнарының, милли гвардия гаскәрләренең, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең һәм органнарының, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү учреждениеләренең һәм дәүләт куркынычсызлыгы органнарының хәрби хезмәткәрләренең, рядовой һәм башлык составлары затларының гаилә әгъзалары, әсирлектә һәлак булган, хәрби хәрәкәтләр районнарында хәбәрсез югалган дип билгеләнгән тәртиптә танылган хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары, инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр ия.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

.